Татарстан Республикасы Зеленодол районы
Ачасыр төп гомуми белем бирү мәктәбе

Фәнни-тикшеренү эше

# “Гасырлардан килгән рухи мирас”

**Эшне башкарды:** 6 класс укучысы
Гатиятуллина Әминә Марат кызы
**Җитәкче:** татар теле һәм әдәбияты
укытуысы Кабирова Г.Р.

Олы Ачасыр авылы, 2022 ел.

Эчтәлек

1. Кереш ........................................................................................... 3 бит
2. Төп өлеш.
1.“Туй” сүзе белән бәйле йолалар................................................4 бит
3. 1.1. Сабан туе......................................................................................4 бит
4. 1.2. Бәби туе ......................................................................................5 бит
5. 1.3. Өй туе..........................................................................................5 бит
6. 1.4.Туй.............................................................................................. 6 бит
7. 2.Башка төрле йолалар.
8. 2.1 Каз өмәсе ......................................................................................7 бит
9. 2.2 Армиягә озату йоласы.................................................................7 бит
10. Йомгаклау .......................................................................................8 бит
11.Кулланылган әдәбият.....................................................................9 бит

## Кереш

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәннәрне онытма син.
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен.
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.
Р.Фәйзуллин

Буыннан буынга күчә торган рухи тәҗрибә һәм йолалар вакытлар узу белән һич тә әһәмиятләрен югалтмыйлар, киресенчә, аларның кыйммәте арта гына. Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребезне, йола, гореф-гадәтләребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә, анда яшәүче һәр кеше гореф-гадәтләрне, йолаларны ихтирам итәргә тиеш .

Туган авылыбыз Олы Ачасыр авылы - борынгы авыл. Әти-әниебез, әби-бабаларыбыз рухын кадерләп саклый. Соңгы елларда авылдашларымның туган җиренә, туган теленә, үткәненә, мәдәниятенә игътибары арткannан-арта бара. Бу үзгәреш йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрне үткәрүгә, онытылганнарын торгызуга һәм яңартуга китерә.

Буыннан-буынга күчеп килгән, бу рухи байлыкларыбыз бүгенге көннәрдә дә безнең тормышыбызның, яшәешебезнең бизәге булып тора. Авылымның халкы үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган.

Тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү безнең авылыбызга хас булып тора. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала.

Бу эшебездә без авылыбыз өчен генә хас булган гореф-гадәтләрне һәм йолаларны элек-электән сакланып килгәнчә күрсәтергә тырыштык.

Максатыбыз: Буыннардан-буыннарга күчеп килгән рухи-мәдәни мирасны барлау һәм саклау;

Бурычлар: 1) Халкыбызның тарихына, сакланып калган гореф гадәтләргә кызыксыну тәрбияләү;

2)Авыл халкы арасында төрле чаралар ярдәмендә пропагандалау.

## Төп өлеш.
## 1. “Туй” сүзе белән бәйле йолалар.
### 1.1 Сабан туе.

Сабантуй – халык бәйрәме. Ул элек яз көне кар беткәч тә, чәчүгә чыкканчы үткәрелгән. Моны, кагыйдә буларак, авыл картлары киңәшеп хәл кылганнар һәм бәйрәмне үткәрү көне турында игълан иткәннәр. Шуның белән бергә, тирә-күрше авыллар ярышларны төрле көнне үткәрергә омтылганнар. Бу күрше авыл кешеләре дә күршеләренең бәйрәмендә катнаша алсын өчен эшләнгән. Ләкин сабан туй ул шул авыл халкының үз бәйрәме исәпләнгән һәм башка авыллардан кунак чакыру гадәте булмаган. Катнашасы килгән күршеләр чакырмыйча гына, мәйданга үзләре килгәннәр һәм бәйгеләр беткәч, гадәттә өйләренә кайтып киткәннәр. Дөрес, бу авылдагы туган-тумачасы һәм таныш-белешләренең ашка чакыруы да мөмкин булган. Ләкин, тулаем алганда, сабан туй кунак чакыру, кунакка йөрешү вакыты булган.

Әйе, ул – олы бәйрәм, һәм аңа хәзерлек алдан ук башланган. Хатын-кызлар Сабантуйга кадәр дип өйләрне юганнар, бөтен нәрсәне чистартканнар. Ирләр исә ишегалдын, урам тирәләрен себергәннәр, чүп-чарларны җыештырганнар . Ат чабышында катнаша торган егетләр атларын чабышка әзерләгәннәр. «Җәйге бакчага» таган эленгән.

Сабантуй бәйрәменә әзерлек сөлге җыюдан башланган. Бу эшне көзен армия сафларына китә торган егетләр башкарган. Алар атлар җигеп, гармуннар уйнап йорт саен кереп сөлге, ситсы, яулык, йомырка җыйганнар. Әгәр йортка былтыргы сабантуйдан соң яшь килен төшкән булса, ул чигүле озын сөлге бирергә тиеш булган. Бу сөлге иң кадерле бүләк булып саналган һәм колганың иң очына бәйләп куелган. Әле киленнәр сөлгенең матурлыгы, бизәлешенең үзенчәлекле булуы өчен дә бик тырышканнар. Чөнки “кем килене, шуның килене” дигән сүз алар өчен бик мөһим булган.

Сабан туен үткәрү өчен махсус урын билгеләнгән. Ул бездә башта «Җәйге бакча» территориясендә булган, аннан май тавы мәйданында үткәрелгән. Һәр авыл өчен билгеле булган көнне, иртәнге якта яисә төштән соң, хөрмәтле аксакаллар җыелган бүләкне мәйданга алып чыкканнар. Иң алдан ир уртасы кеше сөлге-яулыклар, ситсы бәйләнгән колга күтәреп барган. Мәйданда бүләкләрне аерым төр ярышлар өчен атап, билгеләп куйганнар. Ярышлар гасырлар буена килгән тәртип буенча үткән. Элек вакытта ел саен традицион уеннар гына уйнатылган. Бәйрәмне, әлбәттә инде, ат чабышы башлап җибәргән. Ул авылдан читтә, кыр буенда иртәнге якта үткәрелгән. Халыкның күбесе ат чабышын карау өчен махсус еракләрдан кайткан. Атлар күп катнашкан. Иң матур сөлгеләрнең берсен ат чабышында җиңүчегә биргәннәр. Кайчакта иң ахырдан килгән атка махсус атап бирелгән сөлгене такканнар. Соңгы килгән атка бүләкне кызганмаганнар. Күп кенә апалар соңгы атка сөлге бирер идем дип нәзер дә әйтә торган булганнар.

Сабантуйда бик күп төрле уеннарда көч сынашканнар: колгага менү, кузлада капчык ярышы, йомырка кабып йөгерү, капчык киеп йөгерү, аркан

тартышы, катыктан акча эзләү һ.б. Иң әһәмиятлесе, әлбәттә, көрәш булган. Көрәшне кечкенә малайлар башлап җибәргән, аннары яшүсмерләр, егетләр һәм ир-атлар көрәшкәннәр. Иң беренче аксакал көрәшчеләр чыгып бер-ике көрәш элементлары күрсәткән. Көрәш аерым үлчәү бирәмлегендә түгел, ә жирәбә буенча үткәрелгән. Кем кемгә туры килә, шуның белән чирәм өстендә көрәшкән. Бу көрәш кайчак бик озак дәвам иткән, көрәштә җиңүчегә иң зур бүләк – сарык тәкәсе бирелгән.

Сабантуй тәмамланганнан соң кешеләр өйләренә таралганнар. Кич белән бөтен халык “Җәйге бакча”га җыйналган. Анда зур таган булган. Ул таганда егетләр-кызлар 4 пар итеп атынганнар. Ә бакчада төркем-төркем булып гармунчылар тирәсенә җыйналышып җырлаганнар, биегәннәр, рәхәтләнеп күңел ачканнар. Бакча эче халык белән шыгрым тулы булган. Бары төн уртасында гына өйләренә таралышканнар. Мондый кичәләр бер-ике көн дәвам иткән.

## 1.2. Бәби туе

Элек бала тууга бәйле йолаларда бөтен эшне баланы кабул итеп алучы өлкән яшьтәге кендек әбиләре башкарган. Бала туган гаиләдә аларга аерым кадер-хөрмәт күрсәтелгән. Кендек әбисе сабыйның кендеген кискән, аны юындырган. Кендек әбисе бала туганнан соң баланың кендеге төшкәнче килеп йөргән. 3 көн эчендә балага исем кушканнар. Анда мәҗлес җыелган, мулла чакырылган. Мулла баланы мендәргә куеп, азан әйтеп исем кычкырган. Аннары баланың исемен метрика кәгазенә теркәп куйган.

Ир балалар гаиләдә көтелгән бала булып саналган. Чөнки ул нәсел дәвамчысы булып торган. 7 көн үткәннән соң ир баланы сөннәткә утыртканнар. Бала тууның 40 көне хәвефле көннәр булып исәпләнгән. Бу вакыт баланы кеше күзенә күрсәтмәгәннәр, күз тиюдән бишек тирәсенә төрле догалар, миләш агачлары куйганнар. Баланы бишектә йоклатканнар. Бу гадәтләрнең күбесе бүгенге көнгә кадәр сакланып килгән.

## 1.3. Өй туе

Өй туена, гадәттә, туганнар, дуслар һәм күршеләр чакырыла, алар яңа торакны җиһазлауда ярдәм итү өчен акчалата яки әйберләтә бүләкләр китерәләр.

Өй туе хуҗаларга бәрәкәт, сәламәтлек һәм байлык теләп дога кылудан башланып китә. Еш кына өлкәннәр өчен, мулла яисә абыстайны чакырып, аерым коръән ашлары уздырыла. Кичләрен килен чәе үткәрелә торган була. Ягъни йорт хуҗасының хатын-кыз туганнары, дуслары, тирә-күршеләре җыйнала торган була. Күп очракта парлы чәйләр үткәрелгән. Монда инде парлы кешеләр генә чакырылган.

Өй туе XX йөзнең 2 нче яртысында массакүләм торак төзелеше киң колач алган вакытта аеруча еш оештырыла. Шулай ук, йорт төзелешенең аерым этапларында халык йолалары булган: нигез салу, матча кую, мич чыгару һ.б.

## 1.4. Туй

Туй , ягъни яшь парларның кавышу бәйрәме борын-борыннан Сабантуй бәйрәме кебек үк зур итеп үткәрелгән бәйрәм булган.

Өйләнергә теләгән егет кыз өенә яучы карчыкны җибәргән. Яучы карчык шундый зур мисия белән барганда ыштан балагының берсен чыгарып куйганнар. Кызның әти-әнисе әбинең нинди максат белән килгәнен аңлаганнар. Яучы телгә бик оста, бик нык мактый торган, ничек тә ышандыра алу сәләтенә ия булган. Яучылар өчен атнаның мөселманнар өчен изге көне - җомга көн алынган. Яучы үзе шигъри юллар белән дә сөйләшкән. Кыз ярәшергә егет әти-әнисе, якыннан-якын туганнары белән, күрешү-танышу бүләкләре, күчтәнәчләр белән килә, матур сузләр-теләкләр әйтеп нинди ният белән килгәннәрен әйтеп керергә рөхсәт сорыйлар.

Гомумән , җомга көнне кыз ярәшергә киләләр. Ярәшу көнендә әти-әни, бик якын туганнар гына була. Сөйләшү вакытында ишекләр бикләнә, чит кеше кертелми. Туй, аны үткәрү көне-вакыты, кунаклар саны буенча килешү була. Бер-берсен бүләкләү ике яклап та була. Ярәшелгән егет-кыз никах-туй мәҗлесенә кадәр егет-кыз булып калырга тиеш булалар. Элек аларны очраштырмас өчен саклаучы кешеләр дә куелган.

Никах - мөселман динендә егет белән кызны кавыштыруның төп шарты. Никах кыз ягында була. Хәзер мәчетләрдә дә укытыла! Авылда күпчелек очракта никах егет ягында булган. Элек кыз табында утырмаган, чаршау артыннан гына җавап биргән. Соңрак аларны тигез идәнгә бастырып, мулла ризалыкларын сораган. Табында утырмаганнар. Хәзер егет-кыз мөселманча киенеп, никах табынында утыра. Мулла аларның аерым - аерым ризалыкларын үзләреннән, аннан аталарыннан сорый. Аннан никах укыла. Никах вакытында беркем дә комачауларга тиеш түгел, гаилә тыныч, тату корылсын дигән теләк белән ишек-капкалар бикләнә. Никахтан соң егет-кыз бергә кунарга калалар. Алар өчен аерым кияү каләте әзерләнә. Туй вакыты ике як килешуе буенча билгеләнә, шулай ук чыгымнар да.

Егет - кызның иң якын дуслары шаһит була. Шаһитлар барлык туй оештыру мәшәкатьләренә җаваплы. Кәләшкә шаһит-кыз, дус кызлары киенергә булыша. Мәхәббәтләре нык-гомерлек булсын өчен, егет туй күлмәген күрмәскә тиеш диләр, ул элек тә, хәзер дә шулай. Кием, бүләк, балдак алулар күмәкләп хәл ителә. Элек ярәшелгән кыз кияү егетенә никахка кадәр бер кат киемне әзерләргә тиеш булган.

Балдак алышу-гомерлеккә бергә булырга, бер бoжра булырга дигән сүз. Кәләш йортына кияү-егет гади юл белән генә керә алмый, чып-чын имтихан тота, моны кыз-кәләшнең дуслары-туганнары оештыра . Һәммәсенә егет җавап табарга, хак түләргә тиеш.

Туй икенче көнне дә дәвам итә. Мичтә коймак пешерелә, мунча ягыла. Мунчага башта килен белән кияүне кертеп җибәрәләр, тик алар кереп китүгә яшьләр гармун уйнап, җырлап-биеп аларны тизрәк чыгаралар да. Чыкканда

ләгәнгә утыртып тартып кайталар. Аннары кода-кодагыйларны, туганнарны шулай берәм-берәм мунчага кертеп чыгаралар һәм ләгән белән тартып кайталар.

Аннары килен токмач кисәргә тиеш була, килен кискән токмачтан аш пешерелә. Кичен тагын туган-тумачалар җыелып бәйрәм дәвам итә.

Туйның икенче атнасы кыз ягында үткәрелә. Туган-тумачалар, дусишләр җыелып бәйрәм итәләр.

## 2. Башка төрле йолалар.

### 2.1 Каз өмәсе.

Каз өмәсе - көзен, кыш кергәндә казларны өмәләп эшкәртү чарасы. Каз өмәсе – ул матур итеп аралашу, күңел ачу, үзеңне күрсәтү дә булып торган. Каз мамыгыннан мендәр, түшәк, ястыклар ясыйлар. Каз итеннән аш-су өчен бик әйбәтләп файдаланалар.

Татар яшьләре каз өмәсен аеруча көтеп ала торган булганнар. Каз өмәсен бигрәк тә кызлар көтеп алган. Аннан читтә калмас өчен, алар бәбкәләре күп булган апаларга җәйдән үк сүз салып куйганнар. Бу гаиләгә охшарга, яраргa тырышканнар. Йолкыган казларны көянтәгә асып кызлар чишмәгә, су буена алып төшкәннәр. Шул суда казларны юганнар. Гадәттә, гармуннар тагып, кызлар белән бергә егетләр дә чишмәгә төшкән. Су буенда җырлашып-биешеп, төрле уеннар уйнап күңел ачканнар. Казларны юып кайтышка, хуҗабикә каз маенда коймак, тәбикмәк пешереп, чәй әзерләп көтеп торган.

Кичке мәҗлес тәмамлангач, йортта яшьләр уены оештырылган.

Каз өмәсе бүгенге көндә дә үткәрелеп килә. Тик инде ул элекеге кебек үк үткәрелми, тик булышу, ярдәмләшү гадәте әле дә дәвам итә.

### 2.2. Армиягә озату йоласы.

Армиягә китәчәк егет кулына чакыру кәгазе алгач, бөтен туганнарына барып хаер-фатиха алып чыга. Китәр көн алдыннан озату кичәсе үткәрелә. Бу кичәгә яшьләр җыела. Җырлар җырлана, матур теләкләр теләнә. Китәр көнне таң белән йортка мулла килә. Егет бер табак онга учын бастырып түшәмгә кул эзен калдыра. Бу эзне егет армиядән кайтмыйча юмыйлар. Әгәр он коелмаса, димәк егет исән-имин әйләнеп кайта дигән ышану булган. Аннан капкалар киң итеп ачыла да тезелешеп мулла белән сәфәр намазы укыла. Дога кылына һәм егетне дуслары, туганнары озатып китәләр. Яраткан кызы егеткә чигүле кулъяулык бүләк иткән.

## Йомгаклау.

Шулай итеп, без бу хезмәтебездә авылыбызда бүгенге көнгә кадәр сакланып калган гореф-гадәтләрнең һәм йолаларның кайберләренә генә

тукталдык. Әле бездә дини бәйрәмнәр дә сакланып килә. Авылдашларыбыз ифтар мәҗлесләрен үткәрүгә, гает көннәрен билгеләп үтүгә аерым игътибарлы. Кыскасы, халкым һәр бәйрәмгә тиешле дәрәҗәдә игътибар бирә һәм аны буыннан-буынга саклап тапшырып килә. Без, яшь буын да, бу йолаларны онытырга хакыбыз юк!

Мин дә шушы хезмәтем белән, аз булса да, халыкымның гореф-гадәтләрен, мәңге саекмас рухи мирасын барлауда һәм аны саклап калуда үз өлешемне керттем дип уйлыйм. Киләчәктә дә әле безнең алдыбызда бик зур бурычлар тора!

**Кулланылган әдәбият**

1. Баязитова Ф. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары.- Казан: Татар кит.нәшр., 1995;
2. Интернет язмалары.
3. Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре / Татарсан Милли к-ханәсе; Төз.З.Ә.Җамалиева. Казан: милли китап, 2000;
4. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары.-Казан: татар кит.нәшр,1987.